СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*18 октябрь, 1997ел.*
*ШИМБӘ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 118 (8130)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## Указ

**Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләү турында**

Игенчелеккә югары технология кертеп, бөртеклеләрнең гектарыннан 45,2 центнер, тулаем 185 мең тонна ашлык, шул исәптән 109 мең тонна бодай җитештереп, 1997 елда иң югары уңыш алуга ирешкән ***Октябрь районы*** Татарстан Республикасының ***Мактау Грамотасы*** белән бүләкләнә.

**Татарстан РеспубликасыПрезиденты**

**М.Ш.ШӘЙМИЕВ.**

**Казан, Кремль, 1997 ел, 8 октябрь**

## Хөкүмәт телеграммасы

***Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович!***

***1997 нче елда Татарстан игенчеләре үзләренең фидакарь хезмәтләре белән безнең якларда әлегәчә күрелмәгән җиңү яуладылар. Бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 37 центнердан югары уңыш үстерелеп, тулаем ашлык җыемы 6 миллион тоннадан артык тәшкил итә.***

***Шуның белән алар сөекле Республикабызның экономик куәтен ныгытуга, халкыбызның тормыш - көнкүрешен яхшыртуга үзләреннән гаять зур өлеш керттеләр.***

***Бу уңышларда Сез җитәкләгән район игенчеләренең дә олы хезмәте бар. Район эшчәннәрен шушы зур җиңүгә туплый алганыгыз, фидакарь хезмәтегез өчен зур рәхмәт Сезгә.***

***Чын күңелдән Сезне бүгенге Уңыш бәйрәме белән тәбрик итеп, нык сәламәтлек, гаилә бәхете, иминлек, күңел көрлеге, туган Татарстаныбыз һәм күпмилләтле халкыбыз файдасына киләчәктә дә нәтиҗәле, эчкерсез хезмәт итүегезне телим.***

Минтимер Шәймиев.

Казан, 1997 ел, 10 октябрь.

## КОТЛАУЛАР

***Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович! Сезне һәм авыл хезмәтчәннәрен «Уңыш - 97» бәйрәме белән тәбриклибез!***

***Сез менә дигән иген уңышны үстереп сокландыргыч нәтиҗәләргә ирештегез! Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхет һәм уңышлар телим.***

Менделеевлылар исеменнән район хакимияте башлыгы Вахитов.

***Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович!***

***Сезне һәм район хезмәтчәннәрен «Уңыш - 97» бәйрәме белән котлыйбыз. Сезнең ару - талусыз җитәкчелегегез белән район кыска гына вакыт эчендә хуҗалык һәм социаль икътисадый өлкәләрдә зур уңышларга иреште һәм Татарстан Республикасының әйдәп баручы регионнарының берсенә әйләнде.***

***Сезнең киләчәктә дә шулай ук үз эшегезгә бирелгән кеше булып калуыгызны телибез, акылыгыз һәм энергиягез Сезгә Татарстан Республикасы халкына мөмкин кадәр күбрәк файда китерергә булышлык итсен.***

Яр Чаллы шәһәре, эшлиләр Рәфис Кашапов.

***

***Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович! Сезне уракны төгәлләвегез белән котлыйбыз, Сезгә уңышлар, бәхет һәм ныклы сәламәтлек телибез. Җиребезнең чәчәк атуы һәм муллыгы хакына Сезнең белән алга таба да хезмәттәшлек итәсебезгә өметләнәбез.***

Хөрмәт белән В.В.Зуб, А.Е.Романов, С.В.Вычегжанин.

# КЫРДА КУКРӘП ИКМӘК УҢСА, КИЛӘЧӘККӘ ӨМЕТ ТУА



**Ю.В.ТЕРЕНТЬЕВ,** район хакимияте башлыгының беренче урынбасары:

## Редакциянең «Түгәрәк өстәле» артында - авыл эшчәннәре

Мәгълүм булганча, 9 - 10 октябрьдә Республикабыз башкаласы Казанда быел Россия Федерациясе регионнары арасында рекордлы иген уңышы җыеп алуны тәэмин иткән игенчелек алдынгыларын олылауга багышланган тантаналар булып үтте. Бу ике көндә башкала безне, бәйрәмдә катнашучыларны иң кадерле һәм хөрмәтле кунаклар кебек олылады. Безнең өчен шәһәрнең тарихи һәм истәлекле урыннары буйлап экскурсияләр дә, сәнгать осталары концерты да, авыл хуҗалыгы машиналары күргәзмәсен карау да һәм күп кенә башка чаралар да оештырылды.

Шулай да безнең өчен иң истәлеклесе бәйрәм тантаналарында республикабыз Президенты М.Ш.Шәймиевнең, Премьер - министр Ф.Х.Мөхәммәтшин, Дәүләт Советы Рәисе В.Н.Лихачев, министрлыклар һәм ведомстволар, эре предприятиеләр җитәкчеләренең катнашуы булды. Президентыбыз Татарстанда җыелган алты миллион тоннадан күбрәк ашлыкны гәүдәләндергән һәм аңа тапшырылган символик ипине иген кырындагы меңнәрчә батырларның гаять зур хезмәте нәтиҗәсе иттереп баш очына күтәргән мизгел тирән дулкынландыргыч иде...

Без, Октябрь районы вәкилләре дә, күп еллардан соң беренче тапкыр мондый бәйрәмдә үзебезне тантананың тулы хокуклы «гаепләләре» буларак тойдык. Игенчеләребез ирешкән быелгы үрләр турында сөйләүче ул саннарны тагын бер тапкыр искә төшереп үтәсе килә: Ватан амбарларына алар 86 мең тоннадан артык ашлык салдылар һәм шуның 55 мең тоннасы - ашамлык бодае. Бер гектардан 45,2 центнер ашлык җыеп алып, без уңыш 45 центнердан 50 центнерга кадәр булган икенче төркем районнар арасында икенче урынга лаек булдык. «Алга» хуҗалыгыннан комбайнчыбыз Рәшит Насыйбуллин «ДОН- 1500» комбайны белән 40150 центнер ашлык суктырып икенче урынга чыкты. Монда тагын бер бик мөһим фактны да билгеләп үтәргә кирәк. Нибары бер елда район буенча иген уңышы гектардан 23,7 центнерга күтәрелде. Гаять зур бу сикереш беренче чиратта гади игенчеләрнең, хуҗалык җитәкчеләренең аңында революцион үзгәреш ясалу, кыр эшләрендә катнашкан һәркемнең фидакарьлеге нәтиҗәсендә мөмкин булды. Билгеле, бу уңыш аны формалаштыруга зур матди, техник ресурслар тоту, гадәти булмаган оештыру - тәрбия чаралары да үткәрелү нәтиҗәсе дә булып тора. Республика игенчеләребезнең уртак уңышка керткән өлешен лаеклы бәяләде: авыл хуҗалыгы алдынгыларын бүләкләү өчен 600 миллион сумнан күбрәк бүленде һәм ул ел йомгаклары буенча гыйнварда узачак слетта тапшырылачак. Ә республиканың уңыш бәйрәмендә иген уңышы буенча югары күрсәткечләргә ирешкәннәре өчен хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллинга ТР Президентының Мактау Кәгазе һәм исемле сәгате, Мичурин исемендәге хуҗалык рәисе И.Н.Мөхәммәтовка II дәрәҗәдәге диплом һәм исемле сәгать тапшырылды, «Алга» комбайнчысы Р.К.Насыйбуллин һәм уракта МТСның җыелма отряды составында «Кейс» комбайнында катнашкан В.В.Булатов 15әр миллион сум акчалата премиягә лаек булдылар.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

## *Икенче урак өсте*

# Французча белсәң дә, үзеңнекен онытма икән шул

Шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында чөгендерне французча игү технологиясе соңгы чутта, чәчүгә тотыныр көннәр җиткәч кенә кертелде быел. Алай да яңача эшләүнең өстенлеген мактап туя алмыйлар. Мактамаслыкмы соң. Гомер - гомергә «Восход»ка чөгендер сирәкләү, чүбен утауга Норлаттан халык йөри торган иде бит. Ә быел әнә авыл хатын - кызлары да чөгендер җиренә эз басмаган дияргә мөмкин. Алтмышар гектарлы өч басуны да Анатолий Петров берүзе эшкәртеп чыккан.

- Хатын - кызларга түгел, чәчеп чыкканнан соң үземә дә чөгендер җиренә керергә туры килмәде быел,- ди звено башлыгы Сергей Михайлович Сергеев. - Аңа карап, басуларны елдагыдан чүплерәк диеп булмый. Әле менә бу соңгы басуны эшкәртергә чират соңрак җитте, алай да әллә ни зарланырлык түгел. Ә беренче ике басу тагын да чистарак, чөгендерләре дә эрерәк иде...

Шулайдыр, хуҗалыкның быел чөгендер тапшыруда беренче көннәрдән үк югары темп алуы һәм инде килешү йөкләмәсен дә тутырып килүе үзе үк раслап тора бит моны. Татлы тамыр урагына чыккан механизаторларның йөзләрендәге канәгатьлек тә иң элек эшнең шулай уңышлы баруыннан дип чамаладык. Әле менә Сергей Михайлович белән Николай Иванович Абрамов беренчесенең БМындагы хәрәкәт күчергеч тартманы төзәтүне дә сыкранусыз - нисез, уен - көлке белән башкаруларына исең китмәле иде. Баксаң, быел хуҗалыктагы чөгендернең яртысыннан артыгын икесе казытып чыкканнар икән һәм бу хакта горурлык белән әйтәләр. Хәер, горурлану гына түгел, мактансалар да урынлы. Быелгыдай тыгызланган, чөгендерне балчыгыннан аерып ала алмаслык иткән кырларда француз комбайны бик авырлык белән генә барганда боларның комплексы эх тә итмичә эшләп тора бит. Үзләре энәсеннән җебенә кадәр тикшереп әзерләп алып чыккан комбайннар шул. Үзләре дигәннән, Сергей Михайлович, инде әйткәнебезчә, чөгендер өчен баштанаяк җаваплы механизатор, ә Николай Иванович бу эштә, үзе әйтмешли, «ялланган» кеше генә. Дөрес, анысын шаярып кына әйтүе, чөнки, төп эше авыл мәдәният йортында булса да, бер елны да чөгендер урагыннан калганы юк. Менә быел да шул иске комбайнны баштанаяк ремонтлап чыккан һәм шуңа күрә КСының әле бер дә сынатканы юк. Чөгендерне күчләргә ташып торучылар да тоткарлык ясамыйлар бит. Николай Капитоновның КамАЗы, Анатолий Антоновның «Беларус»е гел хәрәкәттә. Хуҗалыкта Петр Абрамов һәм Юрий Кузнецов эшли торган тагын бер комплекс булуы да ярап тора. Димәк, көне булса, хуҗалыкта чөгендер урагы якын көннәрдә төгәлләнәсе. Ә татлы тамырны быел килешү йөкләмәсеннән тыш та шактый тапшырачакларына шикләнмәскә мөмкин.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

**Газетаны басарга әзерләгәндә заводның чимал лабораториясеннән хәбәр итүләренчә, хуҗалык, 2800 тоннадан артык чөгендер тапшырып, 17 октябрьдә килешү йөкләмәсен арттырып үтәгән.**

**Игенчеләрнең уңыш бәйрәменә зур бүләге бу.**

## ФОТОРЕПОРТАЖ



Сергей Сергеев



Николай Абрамов



Н.Азизов фотолары.

